# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге
Акбаш торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

**18.12.2021 ел** **№1**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2021 елның 18 декабрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

-Акбаш торак пунктында зират территориясе коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү нигезендә эшләр өчен түләү).”

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 317 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 164 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
164 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыенытүбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Акбаш торак пунктында халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип исәпләргә.
2. “2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:
-Акбаш торак пунктында зират территориясе коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү нигезендә эшләр өчен түләү).” - карарын кабул ителгән дип санарга.
3. Акбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен халыкка игълан итәргә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен юлларга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Синагатуллина